**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлегенең Кабан-Бастрык торак пунктында 2023 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында гражданнар җыены**

# КАРАРЫ

25.11.2022 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Дүрт-Мунча авыл җирлеге Кабан-Бастрык торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Дүрт-Мунча авыл җирлеге Кабан-Бастрык торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, шул исәптән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Бастырма елгасы аша зиратка җәяүлеләр күперен ремонтлау.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә (Дүрт-Мунча авыл җирлеге Уставының 69 п.5 статьясы) Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «авыл җирлекләре» бүлегендә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Дүрт-Мунча авыл җирлеге башлыгы Р.Т.Ситдыйков